**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

2020 елның 18 декабре №19

Бюджетара трансфертлар бирү
тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль Законының 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Җирлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен район бюджетына кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бишнә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**

Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль районы
Бишнә авыл җирлеге Советының 2020
елның 18 декабрендәге 19 номерлы
карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль Законының 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе билгеләнә.

- **Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан (алга таба-җирлек бюджеты), Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына (алга таба-район бюджеты) бюджетара трансфертлар бирү нигезләрен һәм шартларын, шулай ук әлеге акчаларны тотуны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

1.2. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара трансфертлар тапшырыла.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

- **Башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе һәм шартлары**

2.1. Җирлек бюджетыннан район бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү нигезләре булып тора.

2.1.1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең (алга таба-авыл җирлеге) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тиешле карар кабул итү.

2.1.2. Җирлек башкарма комитеты һәм Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне бер өлешен тапшыру турында килешү төзү.

2.2. Акчалар күләме һәм бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында җирлек Советы карары белән, шулай ук агымдагы финанс елына бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү юлы белән раслана.

2.3. Бюджетара трансфертлар җирлек бюджетының җыелма бюджет язмасы белән расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә вәкаләтләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә бирелә.

2.4. Муниципаль район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар бюджет классификациясе буенча керемнәр составында исәпкә алына, шулай ук максатчан билгеләнеше буенча җибәрелә һәм тотыла.

## 3. Бюджетара трансфертларны куллануны тикшерү

3.1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүдә билгеләнгән срокларда һәм рәвешләрдә җирлек башкарма комитетына кушымта нигезендә башка бюджетара трансфертларның акчаларын тоту турында хисап бирә.

3.2. Максатчан билгеләнеше булган, агымдагы финанс елында кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар чираттагы финанс елында шундый ук максатларга, әлеге трансфертларга ихтыяҗ булганда, бюджетара трансфертлар буенча бюджетлар арасындагы исәп-хисаплар нигезендә җирлек бюджеты турындагы карар нигезендә җирлек бюджеты турындагы карар нигезендә, кулланылырга мөмкин. Күрсәтелгән трансфертларга ихтыяҗ булмаганда, чираттагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар РФ БК 242 статьясы нигезендә җирлек бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

3.3. Бюджетара трансфертларны тотуны **«Яшел Үзән муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе** контрольдә тота.

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Бишнә авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында кушымта

# ХИСАП

## Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан бирелгән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлардан файдалану турында

___________ 20___ ел

| Калганы 01.01. 20__ | Керде | Вазыйфаи затлар саны | Чыгымнар | | | Калганы 01.02. 20__ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | хезмәт өчен түләүгә чыгымнар | матди-техник тәэмин итүгә чыгымнар, барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 13 |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |